КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

2020 ел, 16 июль г.Казань № 599

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актлар нормалары гамәлдә булуын туктатып тору турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 18 июнь, 498 номерлы карарына теркәлгән кушымтага үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актлар нормалары гамәлдә булуын туктатып тору турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 18 июнь, 498 номерлы карарына, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 18 июнь, 498 нче
карарына кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 16 июль, 599 нчы
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының
2021 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булуы
туктатып торыла торган аерым актлар нормалары
исемлеге

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль проектлар конкурсларын үткәрү турында» 2005 ел, 7 апрель, 167 нче карары.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль әһәмиятле проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2009 ел, 8 июнь, 373 нче карары.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында студентларның хезмәт отрядларына булышлык күрсәтүгә һәм аларны үстерүгә юнәлтелгән социаль әһәмияттәге проектларны тормышка ашыра торган коммерциячел булмаган оешмаларга грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 20 май, 330 нчы карары.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны һәм программаларны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләренә грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 6 август, 539 нчы карары.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкара һәм бөтенроссия спорт ярышларында югары уңышларга ирешкәннәре өчен спортчыларга һәм тренерларга дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2018 ел, 20 февраль, 98 нче карарының 1 нче пунктындагы дүртенче абзацы.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлек гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 26 ноябрь, 1082 нче карары.